РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** **Карар**

07.04.2023 Чистай шәһәре №47

Муниципаль ихтыяҗлар өчен күпфатирлы
торак йорттагы җир кишәрлеген һәм
торак урынны тартып алу турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 53.2 статьясы, 56,3 статьясы һәм 56,6 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Авария хәлендәге йортлар исемлеген раслау турында»гы 2013 елның 28 октябрендәге 124 номерлы карары, «Күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында»гы 2017 елның 5 июлендәге 130 номерлы карарлары нигезендә, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**

1. Авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип танылган күпфатирлы йорт янындагы җир кишәрлеген муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алырга. (1 нче кушымта нигезендә).
2. Авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йорттагы торак урынны сатып алу юлы белән алырга (2 нче кушымта нигезендә).
3. Әлеге карар чыгарылган көннән алып 10 (ун) көн эчендә:
- аны массакүләм мәгълүмат чараларында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы”нда бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;
- 1 нче һәм 2 нче кушымталарда күрсәтелгән торак урыннар һәм җир кишәрлекләре милекчеләренә әлеге карарның күчермәсен һәм күчемсез мөлкәтне тартып алу турында килешү проектын җибәрергә.;
- әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте идарәсенең Чистай бүлегенә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Шәһәр Башкарма комитетының
_____________елгы ______номерлы
карарына 1 нче кушымта

| № т/н | Җир кишәрлегенең урнашкан урыны | Кадастр номеры |
|---|---|---|
| 1 | Чистай шәһәре, К.Либкнехт урамы, 9 йорт | 16:54:100305:5 |

Шәһәр Башкарма комитетының
_____________елгы ______номерлы
карарына 2 нче кушымта

| **№ т/н** | **Торак урынның адресы** | **Кадастр номеры** |
|---|---|---|
| 1 | Чистай шәһәре, К.Либкнехт урамы, 9 йорт, 2 фатир | 16:54:100305:127 |

№ _________________________ от _____________________________

***Распоряжение*** ***Боерык***